Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Мәмәшир авыл жирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2023 елның 13 октябре № 5

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мамашир авыл жирлегенең Тәмәй авылында гражданнар жыены уткәрү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл жирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл жирлегенең Тәмәй авылында 2023 елның 24 октябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләргә. Авыл мәчете бинасында халык жыены үткәрү.Тәмәй авылы, Ленин ур., 2А.

2.Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне раславга: " Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегэ , 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә житкән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган куп балалы гаилэлэрдэн,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2024 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?:

- Тәмәй авылындагы урам - юл челтәрен төзекләндерү,ремонтлау , щебенка жэю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Тәмәй авылы территориясен төзекләндерү, балалар мәйданчыгы урнаштыру , балалар мәйданчыгы өчен МАФлар сатып алу , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

- Тәмәй авылында урамнарны яктыртуны җайга салу өчен урам яктырткычлары һәм махсус жиһазлар сатып алу .

- янгын гидрантларын комплектлау өчен сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру ;

" ӘЙЕ " « КАРШЫ"»

3.Халык жыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

4. Халык жыенын Мәмәшир авыл жирлеге башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамашир авыл жирлеге башлыгы И.Г Әхмәтжанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702